ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
______________

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№** __________

2013-2016 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага кертелгән авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип танылган авария хәлендәге торак фондын бетерү һәм «ТР Президенты каршындагы ДТФ» коммерцияле булмаган автоном оешмасына җир кишәрлекләрен түләүсез куллануга бирү турында

2003 елның 6 декабрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Торак кодексының 15 , 32 статьялары, « Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану буенча һәм күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында нигезләмә»нең 49 п., РФ Җир кодексының 39.10 ст., 2нче өлеше, 15нче пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган автоном оешмасына авария хәлендәге күп фатирлы торак йортларны ликвидацияләү (сүтү) турында килешү төзергә тәкъдим итәргә (исемлек кушымтада бирелә);
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган автоном оешмасын, тиешле ышанычнамә биреп, ликвидацияләнә торган авария хәлендәге объектларга милекчелек хокукын туктатырга вәкаләтле итеп билгеләргә.
3. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган автоном оешмасына күп фатирлы йортны ликвидацияләгәннән(сүткәннән) соң күчемсез милекнең дәүләт кадастрыннан

авария хәлендәге объектларны кадастр исәбеннән алу турында гариза белән «Росреестрның Федераль кадастр палатасы» ФДБУ Татарстан Республикасы буенча филиалына , ЕГРПда авария хәлендәге объектка милек хокукын туктатуны дәүләт теркәве турында гариза белән Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына торак биналар һәм тулаем күп фатирлы йортларны күчемсез милек объектларының дәүләт кадастрыннан чыгарганнан соң, 10 (ун) календарь көн эчендә түбәндәгеләрне «ТР Президенты каршындагы  Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган автоном оешмасына төзелеше чорына түләүсез куллануга тапшырырга:

- җирлек җирләреннән (торак пунктлар җирләреннән) җир кишәрлеге , кадастр номеры 16:49:010720:29, ТР, Зеленодольск шәһәре, Бауман урамы, 1нче йорт адресы буенча урнашкан, әлеге карарга кушымта итеп бирелгән кишәрлекнең кадастр планында күрсәтелгән чикләрдә, гомуми мәйданы - 940 кв. м.;

- җирлек җирләреннән җир кишәрлеге (торак пунктлар җирләре), кадастр номеры 16:49:010720:40, ТР, Зеленодольск шәһәре, Бауман урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан, әлеге карарга кушымта итеп бирелгән кишәрлекнең кадастр планында күрсәтелгән чикләрдә, гомуми мәйданы - 600 кв.м;

- җирлек җирләреннән (торак пунктлар җирләреннән)җир кишәрлеге , кадастр номеры 16:49:010720:46, ТР, Зеленодольск шәһәре, Волгоград урамы, 1нче йорт адресы буенча урнашкан, әлеге карарга кушымта итеп бирелгән кишәрлекнең кадастр планында күрсәтелгән чикләрдә, гомуми мәйданы - 1039 кв.м;

- җирлек җирләреннән (торак пунктлар җирләреннән)җир кишәрлеге , кадастр номеры 16:49:010720:27, ТР, Зеленодольск шәһәре, Крылов урамы, 2а йорты адресы буенча урнашкан, әлеге карарга кушымта итеп бирелгән кишәрлекнең кадастр планында күрсәтелгән чикләрдә, гомуми мәйданы - 639 кв.м;

- җирлек җирләреннән(торак пунктлар җирләреннән) җир кишәрлеге , кадастр номеры 16:49:010720:17, ТР, Зеленодольск шәһәре, Крылов урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан, әлеге карарга кушымта итеп бирелгән кишәрлекнең кадастр планында күрсәтелгән чикләрдә, гомуми мәйданы - 605 кв.м;

- җирлек җирләреннән(торак пунктлар җирләреннән) җир кишәрлеге , кадастр номеры16:49:011005:10, ТР, Зеленодольск шәһәре, Футбол урамы, 17 нче йорт адресы буенча урнашкан, әлеге карарга кушымта итеп бирелгән кишәрлекнең кадастр планында күрсәтелгән чикләрдә, гомуми мәйданы - 907 кв.м.

5. «Зеленодольск муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планын «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган автоном оешмасына тапшыруны тәэмин итәргә.

6. «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган автоном оешмасы белән түләүсез куллану килешүе төзергә, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган автоном оешмасына җир кишәрлекләренә кадастр өземтәләрен тапшырырга.

7. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган автоном оешмасына кабул итү-тапшыру акты буенча карарның 4 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен түләүсез куллануга тапшыруны гамәлгә ашырырга.

8. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 августындагы «Зеленодольск шәһәре йортлары сүтелергә тиешле дип тану турында» 2151 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

9. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы сайтында урнаштыруны яисә «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгаруны тәкъдим итәргә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017елның 31 октябрендәге
2726 номерлы карарына
кушымта

Авария хәлендәге торак фондын ликвидацияләү турында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган автоном оешмасы килешүенә кертелгән күп фатирлы торак йортлар исемлеге.

1. Зеленодольск шәһәре, Бауман ур., 1 нче йорт;
2. Зеленодольск шәһәре, Бауман ур., 12нче йорт;
3. Зеленодольск шәһәре, Волгоград ур., 1 нче йорт;
4. Зеленодольск шәһәре, Загородная ур., 1 нче йорт;
5. Зеленодольск шәһәре, Крылов ур., 2а йорты;
6. Зеленодольск шәһәре, Крылов ур., 7нче йорт;
7. Зеленодольск шәһәре, Подгорная ур., 3 нчейорт;.
8. Зеленодольск шәһәре, Футбол ур., 17 нче йорт.